**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне камилләштерү максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2024 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге ПУ-944 номерлы һәм 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-665 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-243 номерлы Указы (Татарстан Республикасы

Президентының 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» 2020 елның 15 августындагы ПУ-499 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» 2022 елның 19 августындагы ПУ-576 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-665 номерлы указлары нигезендә билгеләнгән вазыйфаи окладлары (алга таба – хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары) күләмен арттырырга.

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләгәндә, әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте территориаль органы җитәкчесе секретареның вазыйфаи окладı күләмен 1,05 тапкырга индексацияләргә һәм ул 13 323 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге ПУ-944 номерлы һәм 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-665 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктның 3 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктның 4 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны

финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны үтәүне тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә элек чыгарылган актларын әлеге Указга туры китерергә.

6. Әлеге Указ 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 10 май
№ 336